*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2021-2022 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 52**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Иренләшмәгән сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
    **а) [ә];**
    ә) [о];
    б) [у];
    в) [ү].

2. Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
    а) *кайчан*;
    ә) *йоклаганчы*;
    б) *чөнки*;
    **в) *унынчы*.**

3. Искергән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
    а) *чирү*;
    ә) *эшләпә*;
    **б) *мәктүп*;**
    в) *ноутбук*.

4. Фигыль ясагыч кушымчаларны билгеләгез. **(2 балл)**
    а) -ча/-чә, -лап/-ләп;
    **ә) -ла/-лә, -лаш/-ләш;**
    б) -лы/-ле, -чан/-чән;
    в) -чы/-че, -даш/-дәш.

5. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
    ***Иң** татлы тел – туган тел.* (Мәкаль)
    а) теркәгеч;
    **ә) кисәкчә;**
    б) бәйлек;
    в) аваз ияртеме.

6. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Бер иске дус ике яңа дустан ышанычлырак.* (Мәкаль)

**а) *дус;***

ә) *дустан*;

б) *иске*;

в) *бер*.

7. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәгенә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Эше юк **кешегә** көн дә бәйрәм.* (Мәкаль)

**а) тәмамлык;**

ә) аергыч;

б) хәл;

в) ия.

8. Инкяр җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Менә алтын көз җитте.*

ә) *Агачлар алтын күлмәкләрен киделәр.*

**б) *Бүген көн салкын түгел.***

в) *Әкрен генә яңгыр ява.*

## II. Теоретик бирем.

Күпноктапар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(8 балл)**

***Саңгырау*** *тартыклар шаудан тора. Сүзләр туры һәм* ***күчерелмә*** *мәгънәдә булырга мөмкин. Тезмә сүзләр ике яки икедән артык сүздән тора һәм* ***бер*** *мәгънә аңлата. Сыйфат ияреп килгән исем* ***сыйфатланмыш*** *дип атала. Иярүче һәм* ***тезүче*** *теркәгечләр була. Тәмамлыклар туры һәм* ***кыек*** *була. Аныклагычлар өтер, сызык, ике нокта һәм* ***җәяләр*** *ярдәмендә аерымлана. Баш кисәкләрдән генә торган җөмлә* ***җыйнак*** *җөмлә була.*

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(16 балл)**

*В прошлом веке жил интересный человек – Владимир Иванович Даль. Главным делом его жизни было – собирать слова.*

*Даль изъездил всю Россию в поисках неизвестных ему слов, выражений. Он узнал их в походе, в крестьянской избушке, на ярмарке, на корабле, в рыбацкой артели. Владимир Иванович записывал их в тетради. Он отмечал,*

*из какой местности слово, толковал смысл каждой пословицы, поговорки. Собранные сокровища он поместил в четырёх томах большой книги – словаре. Даль сберёг для народа живой русский язык.* (Интернеттан)

2. Татар телендә нинди сүзлекләр бар? Сүзләрне җыю, сүзлекләр төзү ни өчен кирәк? Шул хакта 12 җөмлә төзеп языгыз. **(12 балл)**